


Чаян

ISSN 0134-384X

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * АПРЕЛЬ * 2016 * КАЗАН



Теманың дәвамы – 10-11 нче битләрдә.

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Украина сәясәтенең парадокслары: Панама офшорларында президент Порошенко тотылган, ә отставкага премьер Яценюк китә.

- Сүриядә Пальмираны миналардан чистарткан сапёрларны Россиядә көтәләр. Чиратта – икътисад МИНистрлыгы, мәдәният МИНистрлыгы, сәламәтлек саклау МИНистрлыгы һәм башка МИНалар.

- Евровидение финалчыларын мельдонийга тикшерәчәкләр.

- Галимнәр яңа кагыйдә чыгарган: мәгариф системасы никадәр буталчыграк булса, үсеп килүче буын күзлегеннән хөкүмәт шулкадәр акыллырак күренә.

- Россиядә юл полициясе яңа эш ысулларын үзләштерә. Радар күбрәк күрсәтсен өчен, алар якынлашып килүче автомобильгә каршы йөгерә.

- «Мин телевизор карамыйм» хәрәкәтенә алмашка «Мин Фейсбукка кермим» дигән яңа хәрәкәт барлыкка килгән.

- Галимнәр, борынгы ирләрнең хатыннарны сөйләшергә көч белән түгел, ә үгетләү белән алырга карар кылганнан соң, өйрәнгәннәрен исбат иткәннәр.

- Сезон яңалыгы: модага тагын ирләргә охшаган ирләр керә.

- Пенсия фондыннан грант алган галимнәр төркеме кешенең 95 яшькә кадәр эшли алуын исбатлаган.

- Бөтендөнья допингка каршы көрәш агентлыгы рус баһадирларының атаклы батырлыкларын шик астына куйган.

- Россия консерваторияләрендә виолончель бизнес-классына студентлар кабул итү башланган.

- Медиклар ачыклаган: хәзерге балалар, тоткыннарга караганда, саф һавада сирәгрәк булалар.

Эрнест ДЫШАЕВ



ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Минем фикеремчә, чыгырларыннан чыккан коллекторлар белән нишләргә икәнен хакимият үзе дә белми. Берәүләр ул ярымбандит оешмаларын тыярга, икенчеләре бурычы булганнарны закон буенча «кысарга» тәкъдим итәләр...

Р. ШИҺАПОВ

БАУЛЫ

Хатны без могтәбәр Шомбай агага күрсәттек.

– Миңа калса, – диде аксакал, **– мин аларны Украинага җибәрер идем. Россиягә тиешле бурычларны кайтарырга...**



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Мин үз гомеремдә беренче тапкыр соңгы прогул ясадым. Җитәкчелектән минем белән мондый очракларның кабатланмавын үтенәм.

Аерылышканнан соң мин үземә урын таба алмыйча йөрдем, бары тик аракы гына минем йөрәк ярама дәва булды.

Минем каршыма Кавказ милләтле кепка кигән кеше килеп басты...

Мине сакчы танымау сәбәпле, эшкә соңарып килдем. Дүшәмбе көнне йөзем пропусктагы фотога охшамаган иде.

Мин әшәке сүзләр белән түгел, ә башка тәгъбирләр белән сүгендем...

(аңлатмалардан)

Рәис ГАЙНЕТДИНОВ

УРЫН АЛЫШТЫРУДАН...

Балачактан ук беләбез
Арифметик кануннар:
Сумма үзгәрмәскә тиеш
Урын алыштырудан.

Ә тормышта бик еш кына
Башкача була икән.
Урын алышса, сумма да
Үзгәреш ала икән.

Бу фикергә эш урынын
Алышканнан соң белдем.
Иске урында йөз сумга
Күберәк ала идем.

ТАБЫШМАК

Үлем-җитем арта бара,
Бала-чага аз туа.
Салымнар бугаздан буа –
Мондый хәл кайда була?

АПТЫРАМЫШ

Бәла-афәт үтеп киткәч,
Куркаклар батырая.
Ирләреннән аерылгач,
Хатыннар матурая.

Валерий ТАРАСЕНКО



Вәлиулла АЙБАШЕВ

ТОРМЫШ КҮЗӘТҮЛӘРЕ

Безнең заманда гаилә башлыгы булып ешрак кредит бирүче банк булып чыга.

Гомер ике өлештән тора. Башта акыл җитми, аннан соң – сәламәтлек.

Чит кеше тормышы – кеше тәрәзәсе кебек. Анда гөлләр тора икән, бу әле алар артында оҗмах дигән сүз түгел.

Үз тормышыңны катлауландырудан да гади нәрсә юк.

Тормыштан бөтен мөмкин нәрсәне дә ал! Ә мөмкин булмаганын... ал, тик бик сак кына...

Эчке бушлыкны бернинди дә Интернет белән тутырып булмый. Ә менә Интернетны үз бушлыгың белән – күпме телисең!



Валентин ДУБИНИН



Гербалайф, әкияти тузан суырткычлар, миллионлы призлар һәм башка ыштансыз калдыра торган «лохотрон»нар безне бернәрсәгә дә өйрәтмәде, ахрысы. Беренче чиратта, бу – җәмгыятьнең иң беркатлы һәм тиз ышанучан катлавы – хатын-кызларга кагыла. Әгәр дә мошенник аларның тышкы кыяфәтенә игътибар иткән икән, бу инде чибәркәй аның кулында дигән сүз. Һәр хатын-кыз заты гүзәллегенә еллар җиле кагылмавын тели бит.

Хәллерәк хатыннарны шомарган хирург һәм косметологлар силикон, ботокс, пластика һәм тәннең төрле өлешләрен «майсызландыру» белән кызыксындыра. Гадирәк, ягъни кесәсе сай булганнарны гүзәллек салоннарында «түләүсез» процедуралар көтә. Бу ысул инде озак еллар буе бик ышанычлы эшләп килә. Телефон йә социаль челтәр аша сезгә түләүсез яшәртә торган салонга чакыру җибәрелә...

Берзаман шундый чакыруга мине дус хатыным капты. Сөйкемле генә ханымның, салонга килгәч, кыяфәте бик үк килбәтле булмавы ачыклана. Аңа тәннең килешә торган 50 мең сумлык бөтен косметика җыелмасы гына ярдәм итә ала икән. Аптырап калган ахирәтемә шунда ук кредит тәкъдим итәләр. «Гүзәллек матди чыгымнар таләп итә, – диләр аңа. – Аның каравы, бу косметика сезне үзгәртәчәк, һәм сез яңа матур тормыш башлаячаксыз!» Салоннан ул чынлап та башка кеше булып чыга: кулында бер чемодан косметика, өстәвенә, елына – 36 процент белән бергә 84 мең сумлык кредит. Бәхет артыннан куып, үзенең адашып ялгыш юлга кереп киткәнен ул өенә кайткач кына аңлый.

Косметик алдау корбаннары үзләренең күндәмлек сәбәбен анык кына атый алмыйлар. Кемдер ачык йөзле менеджерлар сыйлаган чәйдән шикләнә, кемдер гипноз нәтиҗәсе дип уйлый, ә кайберәүләр монда хәтта сихер йогынтысы күрә. Ничек кенә булса да, могҗизалы чемоданны кире кайтарып, акчаларын кире алганнарны бармаклап кына санарга була. Чөнки анда күпсанлы киртәләр туа. Беренчедән, сәүдә кагыйдәләре буенча косметиканың зыянлы икәнен исбатламыйча аны кире кайтарып булмый. Икенчедән, кредит инде рәсмиләштерелгән – аны гамәлдән чыгару мөмкин түгел, килешенүне мошенниклар үзләре зыян күрмәслек итеп төзиләр.


Шулай да күптән түгел Чаллыда алданган ханымнарның берсе Дәүләт алкоголь инспекциясе ярдәмендә килешенүне гамәлдән чыгара, ләкин аңа җиде мең сум крем бәясен һәм кредит буенча процентларын түләргә туры килә. Казаннан бер ханым килешенү текстындагы төгәлсезлекләрдән файдаланып, акчасын суд аша кайтара. Ә күрше Башкортстанда мондый хәл: банк акчаны инде салонга күчерергә өлгергән, һәм чибәрлек корбаныннан ул хәзер кредитны кайтаруны сорый. Фирманың үзеннән, әлбәттә, җилләр искән. Мондый очраклар шәһәр саен йөзләп җыела.

Узган елның ахырында «чемоданнар мәсьәләсе» белән Бөтенроссия халык фронты кызыксына башлады. «Кулланучылар кредиты турында» законына төзәтмәләр әзерләп, намуссыз сәүдәгәрләрне «акылга утыртырга» карар кылынды. Анда өч көн эчендә көчләп тагылган кредит һәм товардан баш тарту мөмкинлеге каралган.

Яңа закон проекты авторлары аны тормышка ашыру өстендә эшләгән арада жуликларның тозакларына эләккән ханымнар саны арта тора. Чибәрлек турындагы буш өметләр артыннан куып, алар мәңге яшь булып түгел, ә мәңге алданган булып калалар.

Людмила САФИУЛЛИНА

Николай КАПУСТА



Ринат МИРЗАЯНОВ





Василий АЛЕКСАНДРОВ



Виталий ПОДВИЦКИЙ





• • •

Транспортта йөрү бәясе артты, бензин, фатирга түләү дә күтәрелде. Ярый әле, ичмасам, хезмәт хакын күтәрмәделәр.

• • •

– Син ит ашыйсыңмы?
— Юк.
— Ә балык?
— Ашамыйм.
— Вегетарианецмы әллә?
— Юк, бюджетник.

• • •

Туташ Юл хәрәкәте инспекциясендә имтихан бирә:

— Тәк, йөртүне сез бирә алмадыгыз!

— Мин әле урыннан кузгалып китәргә дә өлгермәдем ич!

— Ә сез арткы утыргычта утырган килеш ничек кузгалмакчы идегез?

• • •

— Сез бу даруны гомерегезнең ахырына кадәр кабул итәргә тиеш.

— Доктор, ләкин монда бит «Ике ай дәвамында кабул итәргә» дип язылган!

— Ә мин сезгә нәрсә дидем соң?

• • •

Әгәр Ходай американлыларга җәза бирергә теләсә — ул аларга туфаннар җибәрә. Әгәр калган дөньяга җәза бирергә теләсә — ул американлыларны җибәрә.

• • •

– Холмс, җинаятьчеләрне үзгәртә торган чара табылса, ничек яхшы булыр иде. Менә, мәсәлән, карак йә бандитны алабыз. Шалт – һәм ул намуслы кеше, җәмгыятьнең терәгенә әверелә!

— Нәрсә инде сез, Ватсон! Ә намуслы демократик сайлаулар сезгә нәрсәсе белән ошамый?

• • •

Шулай да кызык безнең илдә яшәү. Югары белемең юк, дип, эштән чыгардылар. Дустым укыды, югары белем алды. Барыбер эш таба алмый – эш тәҗрибәсе юк...

• • •

— Сезнең яңа нәчәлнигегез ришвәт аламы?

— Ни сөйлисең син? Искиткеч намуслы кеше! Моңа кадәр мунча директоры булган – бер тапкыр да юынып чыкмаган!

Әнәс МӘХМҮТОВ



Кыш уртасында Шалкановның бакчасында гаҗәеп хәл булды: көтмәгәндә җир астыннан гейзер бәреп чыкты, берничә атна эчендә кар астына күмелгән розалар калкып чыгып чәчәк атты.

Килгән экологлар бердәм фикергә килде: гейзерда гап-гади су. Бераз җылымса гына...

Гади бакча мәйданында ничек итеп Камчатка манзарасы барлыкка килүне белгечләр аңлата алмады. Башларын кашый-кашый түтәлләр арасында әйләнгәләп йөрделәр дә, истәлеккә берничә бәйләм яшел суган алып, китеп бардылар.

Экологлардан соң Гиннесс рекордлар китабы вәкилләре килеп җитте. Алар бик озак бакчаның озынлыгын һәм киңлеген, суның температурасын, үскән җимешләрнең зурлыгын үлчәделәр. Шалкановның кан басымын үлчәгәч, берәр кыяр ашадылар да, машиналарына утырып, юл тузанында югалдылар...

Алар артыннан телевидениедән кунаклар килеп төште. Шалкановны гейзер янында төшергәннән соң, ул вакытка инде өлгереп җиткән помидорлардан авыз итеп, сенсацияле сюжетны эфирга әзерләргә студияләренә кайтып киттеләр.

Озакламый Камчаткадан да делегация килеп җитте. Тәҗрибә уртаклашырга. Пешеп җиткән алма кимерә-кимерә, делегация әгъзалары башларын селкеп йөрделәр дә, кесәләренә орлык өчен алма кимерекләре салып, аэропортка юл тоттылар.

Инде яз якынлашып, бакчада карбыз-кавын һәм виноград өлгергәч, экскаватор белән коралланган төзүчеләр пәйда булды. Алар озак маташмады. Ярты сәгать дигәндә, җир астында калын торба күренде. Аннан кайнар су бәреп тора иде. Суны яптылар, торбаны ямадылар, чокырны күмделәр һәм яңа хезмәт батырлыклары кылырга киттеләр. Берничә дистә карбыз-кавын, биш-алты тәлгәш банан эләктерергә дә онытмадылар, әлбәттә...

Төзүчеләр китте. Ә Шалканов калды. Розалар шиңде, укроп саргайды, бананнар каралды...

Ләкин ул аптырап калмады. Алда җәй бар бит әле! Ул чакта инде бәрәңгесе дә, кыяры, шалканы да җир астыннан үзләре котырып чыгачак. Гейзер һәм шартлаган торбалардан башка.

Виталий ФЕОКТИСТОВ




Иван АНЧУКОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Александр СЕРГЕЕВ



БЕР ФИКЕРГӘ — ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Вәт, мәйтәм, Казанда яисә Уфада светофор кую өчен "рөхсәт"не Мәскәүдән сорарга туры килмәс микән?

Алмаз Хәмзин: Мәскәүдән соранателәнә торгач, без әле җәяү йөрүгә калачакбыз — светофор кирәк булмаячак.

Р. Н.: Алмаз туган, синең белән бәхәсләшергә телим: безне Мәскәү якадан тотмады, маңкорт татар татарны якасыннан эләктерде.

А. Х.: Ә мин бәхәсләшеп тә тормыйм — синең фикерең белән килешәм генә.

Р. Н.: Дөрес әйтелгән сүзне балта белән дә юына алмыйсың.

А. Х.: Үзеңә карата әйтелгәненә, бәлки, син шулайдыр, ә менә үзең башкага әйткәндә балта күтәреп килергә мөмкиннәр.

Р. Н.: Фикердә ялгышсаң — сүзләр, сүзләрдә ялгышсаң җөмлә хөртиләнә.

А. Х.: Җөмләдә дә ялгышсаң, син беркем дә түгел.

Р. Н.: Матурлык хакыйкать балкышы белән тукылган булса гына — чын матурлык.

А. Х.: Бу җөмләдә дә синең чын шагыйрьлегең аңкып тора.

Р. Н.: Яңа яуган карга балалар гына түгел, атлар да сөенә белә.

А. Х.: Сентябрьдә яуганына берәү дә сөенми.

Р. Н.: Йөрәкләрне уеп алырлык җырчылар тагын кайчан туар икән?

А. Х.: Аның хәзер җырдан уелырлык йөрәкләре дә сирәк.

Р. Н.: Сукыр мәхәббәт, адашкан мәхәббәт була… Алмаз туган, син мәхәббәтнең тагын нинди төрләрен беләсең?

А. Х.: Мин әле, син белгәннәреннән башка, саф мәхәббәт барлыгын да беләм.

Р. Н.: Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бетерелгәч, бездә дәрәҗәле берәр исем калдымы соң?

А. Х.: Калды — минем исем!

Р. Н.: Картадан карагыз: Татарстан Россиянең "ашказаны"нда утыра, ә биредән бердәнбер юл — туры эчәккә түгелме?..

А. Х.: Татарстан — ашказаны, Ә Россия бөтен организм дип алсак, сау-сәламәт яшәү чыганагы бездә икән ләбаса!..

Рашат НИЗАМИ

###ҺӘЙКӘЛ

Шаккатамын һәм тел шартлатамын:
Район саен — танк һәйкәле.
Нигә, нигә трактор дустыбызга
Һәйкәлләр юк — шуны әйт әле!..

ТУКАЙ

Лирикада, сәясәттә,
Хөҗү* белән дустыр ул.
Кояшсыз-айсыз торудыр —
Безгә… Тукайсыз тору!





ХАТЫН-КЫЗЛАР МАНТЫЙГЫ

Ирләргә хатын-кыз мантыйгын (логикасын) аңлавы бик кыен. Хатын-кызлар моны үзләренең нечкә хисле булулары, ирләрнең тупас мөгамәләләре, күп нәрсәләрне төшенә алмаулары белән аңлаталар. Аларның сүзләре һәм гамәлләре турында фикер йөртегез әле...

Ире өенә соңарып кайта. – Сөяркә таптыңмы, сөйрәлчек?

Ире өенә иртә кайта. – Син хөрәсән ялкау өчен кем эшләр икән?

Ире бик күп эшли. – Синеңниләр башкарганыңны тикшереп карарга кирәк әле!

Ире аз эшли. – Гаиләне дә туйдыра алмыйсың, имгәк!

Иренең хезмәт хакы күп. – Шундый хезмәт хакы алгач, янга калдырган акчаңның күләмен күз алдына китерәм!

Ире хезмәт хакын күп ала, әмма аз эшли. – Мин бандитка кияүгә чыгарга җыенмаган идем!

Ире хезмәт хакын аз ала, әмма күп эшли. – Шундый акчага канәгать булып, ишәк кебек эшләүче җүләрләрне табарга кирәк бит!

Ире хезмәт хакын күп ала, күп эшли. – Шундый акчалары була торып, хатының өч көн рәттән бер үк тунны киеп йөри!

Ире өйдә хатынына булышмый. – Мин монда хезмәтче-асрау булып урнашмадым!

Ире өйдә хатынына булыша. – Җен алгыры, эш рәте белмәгән килеш диванда ятуың хәерлерәк!

Ире хатынына чәчәкләр бүләк итми. – Кайнананың туган көне булса, чәчәкләр алып кайтасың!

Ире хатынына чәчәкләр бүләк итә. – Күрше узенең хатынына бер кочак розалар бүләк иткән, ә син оялмыйча, миңа өч канәфер чәчәге алып кайтасың!

Ире хатынына ягымлы сүзләр әйтми. – Әниемнең сүзләре хак булган: алар өйләнгәнче генә матур сүзләр әйтәләр!

Ире хатынына ягымлы сүзләр әйтә. – Сине сөйрәлчегең матур сүзләр әйтергә өйрәткәндер әле!

Нияз БИШБАЛТА

МӘКЕРЛЕ ЭШМӘКӘР

Кәримәнең кәҗәсе бар.
Шуңа гаҗиз Маһитап:
Нишләп әле шул корткадан
Сөт алалар гел мактап.

Көнләшүдән Маһитапның
Ыштан бавы шартлыйдыр;
Аныкы да сөт бирә ич,
Күшәп кенә ятмыйдыр?!

Ә беркөнне...
"Сөте әче" дигән хәбәр
"Бетерде" Кәримәне.
Аңа явасы акчалар
Маһига керсен әле!

Теге икән шыпырт кына
(Сизми дә күрше-күлән),
Кәримә кәҗәсен сыйлый
Әремле үлән белән.





Эльвира ДЫШАЕВА





БЕЛЕМГӘ ОМТЫЛУ

Вуз тәмамлаучылар күңел түрендәге максат – дипломга юлның ни дәрәҗәдә авыр икәнен беләләр. Ул максатка ирешер өчен биш ел газап һәм ярты сәгать хурлык кичерергә кирәк, дип шаярталар студентлар. Ә менә Түбән Камадан балалар бакчасы тәрбиячесе, 54 яшьлек Татьяна Т. мондый авыр юллар кичәргә теләмәгән һәм югары белемне... автобус тукталышында сатып алган. Казан университеты дипломы өчен ул 70 мең сум түләгән. Кызганычка каршы, кинәт барлыкка килгән омтылыш «дипломлы белгеч»не, планлаштырылганча, хезмәт хакы артуга түгел, ә җинаять эше кузгатуга китергән.

Илдус АЗИМОВ



АРТЫК ЫШАНГАННАР

«Дөнья читендә» урнашуына карамастан, Буа җәнҗалларга бик бай. Менә әле күптән түгел генә хокук саклау органнарының игътибар үзәгенә «Кыят күптармаклы ЖКХ житештерү предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең элекке генераль директоры Рәфгать Хәсәнов килеп эләкте. Бернichә ел элек ул район мәктәпләре өчен 14 котельный төзергә рөхсәт сорап, җирле Башкарма комитетына мөрәҗәгать итә. Башлангыч хуплана, төзелеш өчен акча бирелә. Берникадәр вакыттан соң котельныйлар эксплуатациягә тапшырыла, ә тагын бер елдан Хәсәнов аларны үз милке итеп рәсмиләштерә. Хакимият вәкилләре яңа объектларны күрергә теләгәч, төзелешнең әле башланмаган да булуы ачыклана. Нәтиҗәдә, директор, мәкерле рәвештә хакимиятнең ышанычыннан файдаланып, район казнасының өч миллион артык акчасын кесәсенә сала.


Илдар НӘФИЕВ



ХӘРБИ УҢЫШ СЕРЛӘРЕ

Хәрби психологлар әйтүенчә, Икенче Бөтендөнья сугышында японнар белән бәрелешләр вакытында американнар мәсьәләләрне тизрәк хәл иткән һәм шуңа күрә дошманны гел җиңеп килгән. Галимнәр моны болай аңлаткан: инглиз телендә сүзнең уртача озынлыгы 5 хәреф булса, япон телендә – 11. Приказ бирергә вакыт ике тапкыр кимрәк киткән, ә бу – кыска бәрелешләр вакытында бик мөһим нәрсә. Кызык өчен, рус теленә дә анализ ясалган: анда сүзләрнең уртача озынлыгы 6 хәреф тәшкил иткән. Ләкин сугыш барганда командирлар тел чисталыгы турында әллә ни кайгырмаган – шуңа күрә җөмләләр еш кына ике тапкыр кыскарак килеп чыккан.




Вячеслав БИБИШЕВ

БЕЗНЕҢ ТУКАЙ

Мәшһүр Габдулла Тукайның кыска гомере белгечләр тарафыннан көненә кадәр өйрәнелгән. Тукайга багышлап фильмнар төшерелгән, спектакльләр куелган, картиналар язылган. Аның иҗаты турында йөзләгән китап, меңләгән мәкалә язылган... Уйлап карасаң, шагыйрь турында бөтен әйтеләсе әйбер әйтелеп беткән шикелле. Шулай да юбилей көннәрендә укучыларга аның тормышы турында берничә сүз әйтеп китү кирәктер.

Шагыйрь кеше арасында басынкы, аз сүзле булган. Сөйләүгә караганда, тыңлауны артыграк күргән. Кешеләр белән Тукай беркайчан да тиз якынлашмаган. Башта күзәтеп өйрәнгән. Мактанчыкларны яратмаган. Алар белән бәхәскә керергә туры килгәндә, бушбугазларны бер үтемле сүз белән урынына куя белгән.

Масаю, тәкәбберлекне беркемгә дә гафу итмәгән. Бервакыт аңа «Кояш» газетасына килгән бер хәбәрне күрсәткәннәр: «Казанга килгән язучы Х. «Минем татар әдәбиятына карашым» дигән темага лекция укыячак». Тукай зәһәр итеп елмайган да, «Бер күз белән» дип өстәп язып куйган. Менә шулай итеп ул билгесез, ләкин үз-үзенә чамадан тыш ышанган тәкәббер язучыдан усал итеп көлгән. Газетада бу белдерү чыкмаган. Әйтергә кирәк, лекция дә укылмый калган.

Яман һәм буш кешеләргә Габдулла тормыш күрсәтмәгән. Аның турында: «Тукайның теленә эләгәргә язмасын!» йә «Тукай шаяртырга яратмый!» дип әйтә торган булганнар. Ә гомумән, шагыйрь уен-көлкене бик яраткан, балалар кебек шатлана, һәм күңел ача белгән.

Берзаман шагыйрь яз көне һава суларга чыга. һәм, кызыксынып, сөяк чөеп уйнаучы балалар янында туктап кала. Күрәсең, күңелендә малайлык хисләре уянып, ул пальтосын сала һәм шау-шулы төркемгә кушыла. Малай-шалайлар белән чын күңелен биреп, отышларга шатланып, уңышсызлыкларга көенеп уйный ул.

– Тынычлан, Габдулла әфәнде! — диганнәр аңа үтеп баручы танышлары. — Синең кебек кешегә үзен болай тоту килешми!

Аларга җавап итеп ул көлә генә:

— Кечкенә чагымда малайларның уйнаганына карап кызыгып тора идем. Ә катнашырга кыймый идем. Инде хәзер уйнап карыйм, ичмасам! Соң булса да, уң булсын...

Менә шундый булган ул Тукай. Кеше һәм шагыйрь.



Илдус АЗИМОВ

Алексей МАМАЕВ



БАСКЫЧ

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар — бик авыр һәм дә озын баскыч.

Кирәклектә бәрабәр булсалар да басмалар бергә,
Югаргы басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә.

Югаргы басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, – ди, –
Ничек гали минем урным, түбәнгеләр, күрәмсез?» — ди.

Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.

БОРЫН

Электә бер кешедә бар иде киң бит, зур ындырдай,
Аның нәкъ уртасында бер борын һәм зур чүгендердәй.

Тәкәббер бу борын, китми исе һич башка мәхлукка;
Олугълыкны сөя торган, чөя торган үзен күккә.

Борын тәхкыйрь итә торган иде бигрәк аякларны,
Диеп: «Сез бик түбән җирдә, ерасыз былчыракларны».

Борынның сахибе бер көн чыга яңгырлы көн юлга,
Каядыр ул бара, һич тә борылмый уңга һәм сулга.

Егылды ул кисәктән, чөнки баткактан аяк тайды, —
Тәкәббер зур борын бик шәп кенә баткакка капланды!

ДӘРӘҖӘЛЕ ЯШҮСМЕР

Тукайның әтисе мулла булган, шуңа күрә Габдулланы бала чактан ук рухани баласы буларак үзен дәрәҗәле, төпле һәм тыңлаучан булырга өйрәткәннәр. Бала бу таләпләрне шулкадәр тырышып үтәгән ки, Кушлавыч авылы кешеләре аны олы кеше кебек кабул иткәннәр. Берзаман бер кеше Габдулланы очратып, аңа ихтирам белән сәлам биргән. Ләкин малай аның исерек икәнен сизеп, аңа кулын бирмәгән. Ни өчен алай эшләдең, дип сорагач, ул «Бәдәвам» юллары белән җавап биргән:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә һәм син алма...

Тирә-юньдәгеләр таң калган, ә диндар яшүсмер турындагы хәбәр бөтен авылга таралган.

САНДУГАЧ ҺӘМ КӨНБАГЫШ

Тукай Уральск шәһәрендә мәдрәсәдә укыган чакта шәкертләр аның яхшы җырлавы турында белгәннәр. Тавышы бик матур һәм көчле булмаса да, Габдулланың бөтен күңелен биреп җырлавы тыңлаучыларга зур тәэсир ясаган. Пәнҗешәмбе көннәрендә шәкертләр бергәләп акча җыеп, көнбагыш, чикләвек сатып алып, кичә оештыра торган булганнар. Габдулла, самавыр артында утырып, чәй салган, һәм сораулар буенча җырлар башкарган. Моның өчен аңа бер уч көнбагыш биргәннәр. Көнбагышы беткәч, ул, көлеп: «Сандугачны ни белән сыйлыйлар?» – дип сораган. Чираттагы учны алгач, ул яңа җыр сузып җибәргән.

КЕМ ДАМА, КЕМ ХАТЫН...

Идел буйлап пароходта сәяхәт иткән чакта Тукай палубада утыручы дүртенче класс пассажирларын күзәтергә яраткан. Монда тормыш бөтен табигыйлыгы белән күз алдында баскан.

«Менә, – дип яза ул рус телендә язылган юл язмаларында, — симергән рус мещанналары бара. Кемдер чәй эчә, кемдер эскәмиягә сузылып яткан. Бер юан хатын, борынын сөртеп, ялгыш кулъяулыгын төшереп җибәрде. Кемдер аңа мөрәҗәгать итте: «Мадам, сез яулыгыгызны төшердегез». Икенчесе әйтеп куйды:

– Нигә син аңа «мадам» дип эндәшәсең? Ул бит дама түгел, ә гади хатын!

– Ә аның аермасы нәрсәдә соң?

— Беләмсең, дустым, дама тар гәүдәле була, а хатын — киң.

Бөтенесе көләләр, ә минем күз алдымда Казанда Державин бакчасының сукмаклары буйлап йөргән дамочкалар һәм Балык базарында квас сатып торган юан хатыннар күз алдыма килә. Башкалар белән бергә мин дә көләм...»



ГАИЛӘ ЧЫГЫМЫ

Хөрмәтле редакция! Заманалар җиңел булмаганлыктан, мин дә балама социаль яклау органнарыннан айга 270 сум пособие рәсмиләштерергә булдым. Үз районымда урнашкан социаль яклау органы бинасына килеп талон алдым, кирәк булачак документлар исемлеге белән таныштым. Исемлек тә бик ышанычлы күренә: баланың туу турындагы таныклыгы, әти-әнинең паспорт белешмәләре, прописка, гариза, әти-әнинең 2НДФЛ белешмәсе, тегелә торган кәгазь папка. Билгеләгән вакытка барлык кәгазьләрне җыеп килдем. Бала авырып больничныйда утыру сәбәпле, соцстрахтан тагын бер белешмә барып алырга туры килде. Ник дисәң дә, гаилә кереме икән ләбаса. Ул белешмәне алыр өчен тагын талон алырга туры килде. Ярты ел саен әлеге документларны туплауны кабатлап торырга туры киләчәк икән. Бәлкем, безнең гаиләнең кереме арткандыр... Менә ул очракта инде безнең бу пособиене алырга хакыбыз юк!

Нәтиҗәдә, үткән вакытны, юлга киткән акчаларны, эштән сорап киткән көннәрне санадым да, дәүләт ярдәменнән башка да яшәрбез дигән фикергә килдем...

Ә. ГОБӘЙДУЛЛИНА

КАЗАН

ДӨРЕСЛЕКНЕ ТАПМАДЫМ

Кадерле Чаян! Соңгы вакытларда мин сәер хәлләргә юлыга башладым әле. Бәлкем, җиңел булмаган уку программасы да тәэсир итәдер... Күптән түгел генә КДУның төп бинасы янындагы юлны тиешле урында чыкмадың, дип, штраф салдылар. Бәхәсләшеп тормый гына штраф кәгазен алдым. Ике адым да үтмәс борын, "Машина кую тыела" дигән билге астында ике машина торганын күрдем. Әле җитмәсә, җәяүлеләр йөри торган тротуарда куелган. Тәртип саклау хезмәткәрләренең игътибарын шуңа юнәлтмәкче булдым. Ләкин дөреслекне генә таба алмадым. Ул, мине күрмәмешкә салышып, бичара студентларга штраф салуын дәвам итте. Әлеге хәлләрдән соң окулистка язылырга булдым, бәлки, минем күзләрем күреп бетермидер... Автоинспекция хезмәткәре башкалар бозган кагыйдәне күрмәгән кебек, минем дә әлеге хезмәткәрләргә карата ышанычым югалмагае...

А. ГАБДУЛЛИНА,
студент

Ринат БӘШИРОВ



Рушан ГАТАУЛЛИН



ЧАЯН шифаханәсе



Олег ГОНОЗОВ



Пенсионер Тәкәҗановны Авырлык һәм тән коррекциясе үзәгенә түләүсез консультациягә чакырдылар. Ул түләүсез тәкъдимнәрне һәрчак уйламыйча кабул итә иде.

Аны кояштай елмаючан йөзле яшь табибә кабул итте.

— Әйдәгез, сезнең авырлыгыгызны һәм буегызны үлчибез. Үлчәүгә басыгыз!

Тәкәҗановның басуы булды — табибә кычкырып ук җибәрде:

— Сездә симерүнең өченче стадиясе! Ә симергәндә атеросклероз, шикәр диабеты, йөрәк, буын һәм бавыр авырулары барлыкка килә! Без сезгә иң яңа коррекция программасы тәкъдим итәбез! Курсның бәясе – 180 мең сум.

Андый акчалары булмауга карамастан, Тәкәҗанов уйланган кыяфәт ясады.

— Ә ташламалар бармы? — дип сорады ул җитди генә.

— Бар! Тәкъдимне беренче булып кабул итүчегә – биш процент. Ләкин бу таныш-белешләрегезнең егерме телефонын биргән очракта гына.

— Әгәр мин йөзне бирсәм?! Мин ун ел буе йорт старостасы булып тордым!

— Юк! Кирәкми! Түләүсез консультация тәмам. Хушыгыз!

— Ә мең телефон бирсәм?!

— Каян килсен сездә шулкадәр номер?

— Ярый, серен ачам: мин Пенсионерлар берлеген җитәклим.

— Без базарда түгел!


— Ә мин сезнең белән сатулашмыйм, — диде Тәкәҗанов. — Иртәгә үк бөтен оешма әгъзаларына шалтыратып чыгам да, сезнең миннән акча кысуыгыз турында сөйлим!

— Әһемм... Башта ук шулай диләр аны...

Альберт БУЛАТОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Шамил ГОБӘЙДУЛЛИН

КҮҢЕЛСЕЗ КЕШЕЛӘР

Соңгы вакытта бездә хезмәт җитештерүчәнлеге аксый башлады.

Гомуми җыелыш вакытында начальнигыбыз:

— Бу хәлнең сәбәпләрен ачыкларга кирәк! — диде.

— Моның сәбәбе бер генә, — дип сүз башлады плановик Ситдыйков. — Эшләве бик күңелсез. Элгәре, ичмасам, эш арасында мәзәк хәлләр, анекдотлар сөйли идек. Ә хәзер нәрсә? Сөйлисе сөйләнгән, беркемне дә шаккаттырып булмый.

— Ни тәкъдим итәсез соң? — дип сорады начальник.

— Юк, болай гына әйтүем, — дип куйды плановик.

Шулай итеп, юньле-башлы бер карарга да килә алмадык.

Ярый әле очраклы бер вакыйгага тап булдык. Безгә яңа хезмәткәр килде. Ул бик күңелле итеп үзе турында сөйләп бирде. Аннары — без. Шуннан соң бер атна буе мәзәк хәлләр, анекдотлар сөйләштек.

Эшләве күңелләләнеп китте. Үзеннән-үзе шундый лозунг пәйда булды: “Эшкә яңа хезмәткәрләрне мөмкин кадәр күбрәк алырга!”

Начальникка үтенеч җибәрдек. “Штат тулы, — дип җавап бирде ул. — Башка беркемне дә эшкә алып булмый”.

Менә шул чакта безнең плановик Ситдыйков искиткеч зур батырлык күрсәтте.

— Үз теләгем белән эштән китәм! — диде ул. — Минем урынга берәр кызыклы кеше килсен!

Бу башлангычны дәррәү күтәреп алдылар. Плановикка иярергә теләүчеләр бихисап иде.

Начальник:

— Бу җитди эштә тәртипсезлеккә юл куя алмыйм, — диде һәм эштән китүчеләр өчен махсус график төзергә кушты.

Тиздән штат тулысынча диярлек яңарды. Шаярганны бер дә аңламый торган бухгалтер Дәүләтшинның гына эштән китәсе килмәде.


Начальник аны приказ белән чыгармакчы иде, өлгерә алмый калды: график буенча начальникның үзенә чират җитте.

Яңа начальник безнең бухгалтер сыманрак кеше булып чыкты.

— Шаяру — бер нәрсә, эш — бөтенләй икенче нәрсә, — диде ул һәм стенадагы графикны алып ташлады.


Һәм без җиң сызганып эшкә тотындык. Күңел төшенке булса да, хәзер фидакарьләрчә эшлибез.

1973 ел.



Эрнст ГЕЛЬМС, «Чаян» № 22, 1977

– Сез бу йортта яшәгәнсездер, әйеме?
– Юк, бу ишегалды белән безнең бик күп истәлекләр бәйләнгән…




Борис СТАРЧИКОВ, «Чаян» № 16, 1962

Валентин ДРУЖИНИН



Валентин ДУБИНИН



ШАЯРТМЫЙБЫЗ-КӨЛМИБЕЗ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»га быелның 1 апреленнән үк язылырга була (бу шаярту түгел!).

Ә хәзер игътибар! Яраткан журналыгызны проблемаларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары язылы ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!



ЧуАр пресса

ЯСАГАН

Рәссам Малевичның “Кара квадрат”тан ары тагын нәрсә ясаганын беркем дә исенә төшерә алмас, ахры. Бу рәсеме белән ул рәсем сәнгате тарихына нокта куймакчы булган. Ләкин бу мондый стильдә эшләнгән беренче рәсем булмаган. Малевичка кадәр француз рәссамы Алле Альфонс Вивьен Галереясында “Төнлә тау куышында негрлар көрәше” исемле кап-кара полотносын күрсәтергә куйган була.

БАРЫП ЧЫККАННАР

Европа үзенең иреклле гадәтләре белән тирә-юньдәгеләрне һаман шаккаттырып тора. Голландиядәге автомәктәп инструкторларына уку өчен гадәти булмаган түләү алырга рөхсәт иткәннәр. Хәзер укучылар машина йөрткән өчен секс белән түли ала. Илнең транспорт һәм юстиция министрлары мондый түләүне законлы дип тапкан. Төп шарты: “түләү” саклану чараларын үтәгәндә генә.

БҮЛЕШӘ АЛМАГАННАР

Зур немец автоконцерны Daimlerда акционерлар җыелышы уза. Чараны ике инвесторның кисәк кенә сугышып китүе туктата. Котырынган бюргерларны полицейскийлар гына тынычландыра. Низагның сәбәбе – акционерларның буфетта бүлешә алмаган сосискалар булып чыга.




Хамид БАХРАМИ (Иран)





САММЕРС (АКШ)




Дейв КИНГ (Англия)



Ги РОДД (Бельгия)



КОВЕРЛИ (Англия)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Әгәр теләсәгез, суд сезгә адвокат бирә ала.

– Рәхмәт, ике юньлерәк шаһит бирсәгез шәбрәк булыр иде.

• • •

– Улыгыз географияне бик начар белә!

– Белсә соң! Безнең керемнәр белән ул барыбер ерак китә алмаячак...

• • •

– Мин дүшәмбе көннәрендә фитнеска йөрим.

– Нигә?

– Дүшәмбе бөтен кешенең дә яңа тормыш башлана. Ә аннан соң туктый – залда һәм бассейнда гомумән беркем юк!

• • •

– Алло, полиция! Ярдәм итегез, мине талыйлар!

– Юлга чыгабыз. Сез кайда?

– Өйдә. Фатир түләвенә яңа квитанцияне өйрәнәм!

• • •

Хөкүмәт утырышы бара.

– Кризис вакытында хөкүмәт кече бизнес, автомобиль йөртүчеләр һәм хезмәт кешеләре турында онытмаска тиеш.

– Тик безнең илдә пенсионерлар, студентлар да бар бит әле...

– Сез хаклы, коллега, алар өчен дә берәр нинди салым уйлап чыгарырга кирәк.

• • •

– Әти, мин йөреп керим әле?

– Әниеңнән сора.

– Әни, йөреп керергә ярыймы?

– Әтиеңнән сора.

Менә шулай балачактан ук бюрократиягә ияләнәбез дә инде.

• • •

– Беләсеңме, кичә бер җирдә укыдым: «Икәү – бернең бәясенә!»

– Нәрсә булган, гади реклама акциясе.

– Бу бит бала тудыру йорты иде!



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры
һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм
массакүләм коммуникацияләр
өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба
(Роскомнадзор)
идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**

Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә
журнал әсәрләрен файдалану тыела.



Белешмәләр өчен
телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Язылу һәм телевизор от!



1 **Язылу**
30.06.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына язылу *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышу аласың)*

2 **Җибәр**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 **От**
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!









Акцияне үткәрү вакыты:18.04.2016 - 20.09.2016

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

РӘСЕМНӘРДӘ 10 АЕРМА ТАП






Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

Кроссворд челтәрендәге сораулар:

- Композитор Алмаз ...
- Әбинең "Дусларым" йомгак. Кыр җәнлеге
- Халык җыры
- Гореф-гадәт, ритуал
- "... исе" (Р. Миңнуллин)
- "һәм" искечә
- Икенче нота
- "Һәр тарафка төмле исләр чәчкәләр бу ..." (Тукай)
- "Иртәгә киттәнче дуслар тәнә җаным торса ..." (Тукай)
- Бөек татар шагыйре
- Җиденче нота
- Урта Азиядә инеш
- (-1) безнең өйберә
- 3,14
- ... Алле (циркта)
- Мифологик кораблъ
- Кан тамыры
- "Ишкәкче ... җыры"
- Хәрби машина
- "Кара ... микән"
- Россиядәге халык
- Мактау шигыре (-1)
- Композитор ... Кальман
- Бер утырып йорт эче тулы ясоы йорт. Иң яшел яшелчә
- Сливага охшаш көньяк җимеше
- Ачы, төче, татлы
- "Күзгә ... (-1) җилләрдә"
- ... (-1) кардәшләр
- Уйлау өчен кирәк. Терәклекнен башы
- "Әй, ... не, шофер, тот туры"
- Хөрмәт (-1) ... се ордены
- Нота
- Язучы ... Ахунов. Ир бала
- Чебеннән ... ясау
- "Зәңгәр ..." (К. Тинчурин)
- Чин салкында һава ярып ялгыры таянычы. 5557 м



1. Яхшы шарту күпме тора?

2. Нефть кыйммәтләнсен өчен нишләргә кирәк?

3. Ярты ел эчендә валюта счёты, ике катлы йорт һәм машина алган кешегә тагын нәрсә кирәк?

4. Диетолог һөнәрендә иң авыры нәрсә?

5. Иң зур сабырлык сорый торган урын.

6. Пелашлану нәрсә ул?

7. Дивандагы зур симез тапны ничек бетерергә?

ЖАВАПЛАР

1. Кайчагында – баш бәясенә. 2. Нефтьне бензиннан ясарга. 3. Акланыр өчен документлар. 4. Ашауны тыяр өчен авыруның иң яраткан ризыгын ачыклау. 5. Бәдрәфе бикләнгән сырахана. 6. Чәч тарауны баш юу белән алыштыру процессы. 7. Аерылышырга гариза бирергә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«СИБЕЛӘ ЧӘЧӘК»**, **«РАМАЙ»**.


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Э. КАМАЛОВА (Актаныш р-ны, Иске Айман ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
Ә. РӘХМӘТУЛЛИНА (Арча),
Ф. САБИТОВА (Яшел Үзән р-ны, Күгеш ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Иске Айман авылыннан **Эльмира КАМАЛОВА!**

КАРИКАТУРА ОСТАЛАРЫ


Мирослав БАРТАК (Чехия)



Карел Чапек һәм Ярослав Гашек кебек сатирик язучылар белән генә дан тотмый Чехия. Бу илдә бөтен дөньяга танылган карикатурачылар да бар. Шуларның берсе – Мирослав БАРТАК. Рәсемнәре озак еллар буе планетаның юмористик басмалары буенча сәяхәт итә. Аның карикатуралары безнең журналга да килеп җитте.











4612750670080